**Татарстан Республикасы Чүпрәле Мунииипаль районы «Иске Чүпрәле беренче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**

# РУС ТЕЛЕНДӘ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘГЕ 9НЧЫ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫНА ТАТАР ТЕЛЕННӘН БЕРДӘМ РЕСПУБЛИКА ТЕСТЫН ҮТКӘРҮ ӨЧЕН МАТЕРИАЛЛАР

Башкарды:
**Тажетдинова М. А.**, югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

# Теманың актуальлеге

- 2012 нче елда Татарстан Республикасының берничә районында эксперимент буларак уздырыла башлаган татар теленнән БРТ 2012 – 2013 нче уку елыннан барлык мәктәпләргә дә гамәлгә кертелде һәм бүген дә дәвам итә. Бердәм республика тестын үткәрү һәм моның өчен материаллар әзерләү мөһим. Белем һәм күнекмәләрне камилләштерү өчен, вариантлар никадәр күбрәк булса; укучылар өчен дә, укытучылар өчен дә шулкадәр отышлырак.

## Максат:

Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендәге 9нчы сыйныф укучыларына татар теленнән бердәм республика тестын үткәрү өчен материаллар (яңа вариантлар) әзерләү

## Бурычлар:

- контроль үлчәү берәмлекләренә билгеләмә бирү, аларның төрләрен һәм әһәмиятен билгеләү;
- татар теленнән бердәм республика тестын башкарганда, рус мәктәбендәге татар төркемнәрендәге укучылар үзләштерергә тиешле белемнәр һәм күнекмәләргә,
- бердәм республика тесты кодификаторларына һәм демовариантларына күзәтү ясау;
- рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендәге 9нчы сыйныф укучыларына татар теленнән бердәм республика тестын үткәрү материалларының һәм җавапларының күрсәтмә вариантларын тәкъдим итү.

- **Тикшеренү объекты** –рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендәге укучыларга татар теленнән белем бирү өчен төзелгән программалар, дәреслекләр, бердәм республика тестына әзерләү өчен төзелгән методик әсбаплардагы материаллар, мәгариф министрлыгы сайтындагы кодификаторлар һәм демовариантлар, Г.Бәшировның “Нурҗиһан”, М.Галиевнең “Нигез”, М. Мәһдиевнең “Торналар төшкән җирдә” әсәрләреннән өзекләр.
- **Тикшеренү предметы** – татар теле буенча КҮМ материаллары
- **Метод һәм алымнар** – гамәлдә кулланыла торган материалларга күзәтүләр ясау, төрле елдагыларны чагыштыру, анализлау, тексттан өзек сайлап алу, яңа вариантларны тәкъдим итү.

# Эшнең структурасы

- **Эчтәлек**
- **Кереш**
- **I бүлек. Контроль үлчәү бирәмлекләренә күзәтү**
  - Нәрсә ул контроль үлчәү бирәмлекләре? Аларның төрләре һәм әһәмияте
  - Бердәм республика тесты кодификаторларына күзәтү
  - Бердәм республика тесты демовариантларына күзәтү
- **II бүлек. Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендәге 9нчы сыйныф укучыларына татар теленнән бердәм республика тестын үткәрү материалларының һәм җавапларының күрсәтмә вариантлары**
- 2.1. Беренче вариант
- 2.2 Икенче вариант
- 2.3. Өченче вариант
- **Йомгак**
- **Файдаланылган әдәбият**

## I бүлек.
## 1.1. Контроль үлчәү берәмлекләренә күзәтү

- Контроль үлчәү берәмлекләре – апробация өчен әзерләнгән ябык яки ачык типтагы тест биремнәре комплекты (варианты). [25]
- Татар теленнән укучыларның белем һәм күнекмәләрен тикшерү юллары
- рус мәктәбендәге татар төркемнәрендәге 9 нчы сыйныф укучыларының мәктәп программасы буенча (Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М., Гарипова В.А.) [13] нинди белемнәр һәм күнекмәләргә ия булуы

# 1.2.Бердәм республика тесты кодификаторларына күзәтү

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан әзерләнгән һәм расланган “Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына 2014, 2015, 2016 нчы елда татар теленнән бердәм республика тестын үткәрүгә әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторлары

Кодификатор ике бүлектән тора:

- 1нче бүлек – төп гомуми белем бирү мәктәбе курсы буенча татар теленнән бердәм республика тестларында тикшерелә торган эчтәлек элементлары исемлеге: фонетика, лексика һәм фразеология; сүз төзелеше, сүз ясалышы; грамматика, морфология, грамматика, синтаксис, орфография, пунктуация;
- 2нче бүлек — төп гомуми белем бирү мәктәбе курсы буенча татар теленнән бердәм республика тестларына әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр исемлеге

## 1.3.Бердәм республика тесты демовариантларына күзәтү

- 2014 нче елда 3 сәгат 55 минут вакыт эчендә өч (А,В, С) өлештән торган эш.
- 2015нче елдан башлап, 2 сәгать 30 минут (150 минут) вакыт эчендә 2 бүлектән торган эш:
- беренче бүлек 20 биремне (1 - 20) үз эченә ала. Беренче бүлектәге биремнәр укылган текст нигезендә эшләнә. 1 – 20 нче биремнәрнең җавапларын эзлекле тәртиптә сүз ( сүзтезмә), саннар ярдәмендә язарга күрсәтелгән. Шул ук текст нигезендә эшләнелә торган икенче бүлектә тәкъдим ителгән (21.1 яки 21.2) ике биремнең берсен генә сайлап алып һәм дәлилле киңәйтелгән җавап язарга. Демовариантларга мәктәп программасындагы барлык бүлекләр кертелгән: фонетика; лексика һәм фразеология; сүз төзелеше, сүз ясалышы; грамматика, морфология, грамматика, синтаксис, орфография, пунктуация.
- Аларның әһәмияте

## II бүлек. Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендәге 9нчы сыйныф укучыларына татар теленнән бердәм республика тестын үткәрү материалларының һәм җавапларының күрсәтмә вариантлары

- Түбәндәге әсәрләрне укып чыктык:
- Г.Бәшировның “Нурҗиһан”,
- М. Мәһдиевнең “Торналар төшкән җирдә”,
- М.Галиевнең “Нигез”.

Шушы әсәрләрдән өзек сайладык.

- 2.1. Беренче вариант.
- 2.2 Икенче вариант.
- 2.3. Өченче вариант.

# Сайлаган текстларыбыз түбәндәге таләпләргә җавап бирә:

- балага бик аңлаешлы, күңеленә якын булырлык;
- яшь үзенчәлегенә туры килә;
- сурәтләү чараларына бай;
- тәрбияви әһәмияткә ия.

Беренче вариант өчен Гомәр Бәшировның “Нурҗиһан” исемле хикәясеннән алынган өзекне чишмә суы белән саф яшьлек хисләрен тәңгәлләштереп, “Чишмәдә” дип атадык. Бу текст укучыда бүгенге көндә бик актуаль булган танышу әдәбе, кеше кадерен белү, соклана белү, булышырга, яхшылык эшләргә омтылу, рәхмәт әйтү кебек сыйфатлар, бәхетле булырга омтылыш тәрбияли.

Икенче вариант өчен алынган М.Мәһдиевнең “Торналар төшкән җирдә” әсәреннән “Туган йорт тәрәзәләре” дип исемләнгән текст туган йорт, әни кебек кыйммәтләрнең кадерен белергә кирәклеген искәртә.

Өченче вариант өчен М.Галиевнең “Нигез” әсәреннән алынган өзек туган якка мәрхәмәтле булырга, туган якка, аның кешеләренә изгелек эшләргә тырышырга чакыра.

# Һәр вариант өчен материалыбыз түбәндәгеләрдән гыйбарәт

- эш башкару өчен күрсәтмә;
- һәр җөмләсе номерланган текст;
- беренче бүлек  өчен тексттан чыгып төзелгән биремнәр;
- икенче бүлектә текст нигезендә сочинение язу өчен биремнәр;
- җаваплар.
- Һәр эш ике бүлектән тора. Икесе дә укылган текст нигезендә эшләнә. Беренче бүлек  20 биремне (1 – 20) үз эченә ала; икенче бүлектә сайлап алып,  дәлилле киңәйтелгән җавап язу өчен, ике бирем тәкъдим ителде (21.1 яки 21.2).

## Проект эшеннән көтелгән нәтиҗә

Бердәм республика тестына әзерләнүне күз уңында тотучы ярдәмлекләрнең күләмен арттыру: өч вариант тәкъдим итү.

Без рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендәге 9нчы сыйныф укучыларына татар теленнән бердәм республика тестына әзерләнү өчен кулланма төзүдә үзебездән өлеш кертергә тырыштык.

## Хезмәтнең фәнни-гамәли әһәмияте

Бердәм республика тестына әзерләү өчен – укытучыларга, әзерләнү өчен – укучыларга, моннан тыш татар теленнән белем һәм күнекмәләрне камилләштерү өчен – студентларга, магистрларга бик файдалы кулланмаларның берсе булыр дип өметләнәбез.